**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 февраль № 103

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 21 апрель, 204 нче; 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2007 ел, 20 апрель, 136 нчы; 2008 ел, 7 ноябрь, 782 нче; 2010 ел, 29 гыйнвар, 43 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 24 август, 695 нче; 2012 ел, 8 ноябрь, 973 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2013 ел, 7 ноябрь, 861 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 20 июнь, 426 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба – Министрлык) хезмәткәрләренең чик санын 828,5 берәмлек дип, вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча хезмәткә түләүнең айлык фондын 3 264,6 мең сум дип билгеләргә, шул исәптән:

117 берәмлек – Министрлык аппараты хезмәткәрләре, вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча хезмәткә түләүнең айлык фонды 579,5 мең сум;

711,5 берәмлек – Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләре, вазыйфаи окладлар, тариф ставкалары буенча хезмәткә түләүнең айлык фонды 2 685,1 мең сум»;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турында нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә);

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлә).

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче

карарына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 21 апрель, 204 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 апрель, 136 нчы карарының 1 пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 7 ноябрь, 782 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 29 гыйнвар, 43 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары турындагы нигезләмәләргә мобилизация әзерлеге буенча функцияләр кертү хакында» 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче карарының 1 пунктындагы утыз алтынчы – утыз сигезенче абзацлар;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 24 август, 695 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Юстиция министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 ноябрь, 973 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 ел, 2 ноябрь, ТРЗ-73 нче Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2013 ел, 2 февраль, 69 нче карарының 7 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру буенча вәкаләтле орган турында» 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы карарының 2 пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 7 ноябрь, 861 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче карарының 1 пунктындагы алтынчы һәм җиденче абзацлар;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан

Республикасы Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 июнь, 426 нчы карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\103.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 22 февраль, 68 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 20 февраль, 103 нче
карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы (алга таба – Министрлык) юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының закон проектлары белән эшләү һәм норма чыгару эшчәнлеген хокукый тәэмин итү һәм координацияләүне, шәхес һәм дәүләтнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүдә ярдәм итүне, Татарстан Республикасының бердәм норматив хокукый актлар банкын булдыруны һәм алып баруны, хокук мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары белән багланышлар оештыруны, Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм матди тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы була.

Министрлык гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү һәм тормышта авыр хәлдә калган гражданнарга кичектергесез очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында карар кабул итү өлкәсендә вәкаләтле ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы була.

1.2. Министрлык үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Министрлык үз эшчәнлеген федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм бүтән оешмалар белән бәйләнештә гамәлгә ашыра.

1.4. Министрлык юридик зат була, аның мөстәкыйль балансы, банк учреждениеләрендә исәп-хисап һәм бүтән счетлары, үз исеме һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гербы рәсеме белән мөһере, бүтән мөһерләре, штамплары һәм билгеләнгән үрнәктәге бланклары була.

1.5. Министрлыкның урнашу урыны – Казан шәһәре, Татарстан урамы, 55 йорт.

II. Министрлыкның төп бурычлары

2.1. Министрлыкның төп бурычлары түбәндәгеләр:

2.2.1. Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак алып бару предметлары һәм Татарстан Республикасының үзе алып бару предметлары буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләре кысаларында юстиция тармагында дәүләт сәясәтен тормышка ашыру.

2.2.2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының закон проектлары белән һәм бүтән норма чыгару эшчәнлегенең шәхеснең һәм дәүләтнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итә торган дәрәҗәсенә ирешү.

2.2.3. Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать судьялары эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итү.

2.2.4. Гражданнарның түләүсез юридик ярдәмгә хокукларын тормышка ашыру.

2.2.5. Хокук мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары белән багланышларны гамәлгә ашыру.

2.2.6. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, вазыйфаи затлар, гражданнар һәм оешмалар тарафыннан муниципаль норматив хокукый актлары турында мәгълүмат алу өчен шартлар тудыру.

## III. Министрлык вазыйфалары

3.1. Министрлык түбәндәге төп вазыйфаларны гамәлгә ашырган өчен җавап бирә:

юстиция тармагында идарә итү (02.04 <*>);

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлеген координацияләү һәм хокукый тәэмин итү (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тикшерүдә тоту) (02.04.01 <*>);

билгеләнгән тәртиптә җәмәгать судьялары һәм аларның аппаратлары эшчәнлеген тәэмин итү (02.04.02 <*>);

3.2. Министрлык үз компетенциясе кысаларында түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

мәгариф белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән (04.05 <*>);

дәүләт финанслары белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән (01.02 <*>);

табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә табигый мохитне саклау өлкәсендә идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы белән (01.06 <*>);

---

<*> Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органнары функцияләре кодификаторы буенча кодын билгеләү.

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән (01.07 <*>);

билгеләнгән тәртиптә хезмәт белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән (01.13<*>);

мәгълүматлаштыру белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән (01.15 <*>);

сәнәгать белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән (03.01 <*>);

авыл хуҗалыгы белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән (03.02 <*>);

билгеләнгән тәртиптә транспорт комплексы белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән (03.03 <*>);

сәламәтлек саклау белән идарә итү вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән (04.02 <*>);

мәдәният өлкәсендә (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм файдалану) мөнәсәбәтләрне җайга салу, төрле диндә булган дини берләшмәләр арасында үзара аңлашу һәм сабырлыкны ныгытуга булышлык итү вазыйфаларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән (04.03 <*>);

физкультура һәм спорт өлкәсендә идарә вазыйфаларын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән (04.04 <*>);

социаль-икътисадый программалаштыру вазыйфасын гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән (01.01 <*>);

балигъ булмаганнарның күзәтүсез калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау белән идарә итү вазыйфаларын гамәлгә ашырганда Республиканың балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе белән (04.06.03 <*>).

## IV. Министрлыкның вәкаләтләре

4.1. Министрлык үз компетенциясе кысаларында һәм әлеге Нигезләмәнең III бүлеге нигезендә түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

4.1.1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының закон чыгару һәм бүтән норма чыгару эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашыра.

4.1.2. Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектларының бергә алып бару предметлары буенча федераль законнар проектларына, Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы президенты указлары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары

проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына имзага кергән Татарстан Республикасы законнарына хокукый экспертиза үткәрә.

4.1.3. Билгеләнгән тәртиптә закон чыгару һәм бүтән норматив хокукый актлар проектларына экспертиза үткәрү, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә башка мәсьәләләрне хәл итү өчен белгечләр һәм экспертлар, дәүләт органнары һәм оешмалары, фәнни һәм бүтән оешмалар хезмәткәрләрен, җәлеп итә, шул исәптән шартнамә нигезендә.

4.1.4. Билгеләнгән тәртиптә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертизаны гамәлгә ашыра.

4.1.5. Билгеләнгән эшчәнлек тармагында Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыра.

4.1.6. Норма чыгару һәм (яки) хокук куллану эшчәнлегендәге мониторинг барышында билгеле булган кимчелекләрне бетерү буенча үз вәкаләтләре кысаларында чаралар күрә.

4.1.7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарының законнарга туры килми торган норматив хокукый актлары үз көчен югалткан дип тану турында, нигезләү һәм тиешле карар проекты белән, тәкъдимнәр кертә.

4.1.8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру эшләрен оештыра һәм яраштыра.

4.1.9. Россия Федерациясе Юстиция министрлыгына ел саен Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингы планы проектына тәкъдимнәр һәм мониторинг нәтиҗәләре хакында доклад тапшыра.

4.1.10. Үз компетенциясенә ярашлы рәвештә федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнары, бүтән россия һәм чит ил органнары һәм оешмалары белән төзелгән шартнамәләр, килешүләр һәм ачык-хокукый характердагы бүтән актлар реестрын алып бара.

4.1.11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелергә тиешле Татарстан Республикасы законнары проектларын татар теленә тәрҗемә итүне гамәлгә ашыра.

4.1.12. Хокукый мәсьәләләр буенча ведомствоара координацияләү эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмат-аналитика ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

4.1.13. Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыручы махсус дәүләт органына ел саен коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру турында хисап тапшыра.

4.1.14. Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән хокукый актларының контроль нөсхәләренең электрон үрнәген «Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы»нда (www.pravo.gov.ru) урнаштыру өчен Россия Федерациясе федераль сак хезмәтенә билгеләнгән тәртиптә тапшыруны тәэмин итә.

4.1.15. Татарстан Республикасы законнарын, норматив характердагы Татарстан Республикасы Президенты актларын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларын, Татарстан Республикасы Министрлар

Кабинетының норматив хокукый актларын «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны гамәлгә ашыра.

4.1.16. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алуны һәм «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны гамәлгә ашыра.

4.1.17. Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкын формалаштыра һәм алып бара.

4.1.18. «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә вәкаләтләр бирелгән органнарның (оешмаларның) «Татарстан Республикасының атказанган юристы» Татарстан Республикасының мактаулы исемен бирү хакында үтенечнамәләрен карап тикшерә һәм тиешле бәяләмәләр әзерли.

4.1.19. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре реестрын алып баруны һәм аннан мәгълүматлар бирүне гамәлгә ашыра.

4.1.20. Татарстан Республикасы Административ-территориаль берәмлекләре реестрын алып баруны һәм аннан мәгълүматлар бирүне гамәлгә ашыра.

4.1.21. Җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә хокукый ярдәм күрсәтү максатларында алар белән багланышларны оештыра.

4.1.22. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрын оештыруны һәм алып баруны гамәлгә ашыра.

4.1.23. Законнарда билгеләнгән тәртипләрдә җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган дәүләт вәкаләтләре үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

4.1.24. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен үтәү белән бәйле мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларыннан билгеләнгән тәртиптә документлар һәм мәгълүмат сората.

4.1.25. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарына оештыру-методик ярдәм күрсәтә.

4.1.26. Муниципаль берәмлекләр тәкъдимнәре буенча иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында фикер алышу һәм иҗтимагый кәефне чагылдыру өчен, шулай ук өстенлекле рәвештә иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча халык фикерен ачык белдерү өчен гражданнар масса күләм булу өчен махсус бүлеп бирелгән яки җайлаштырылган бердәм урыннарны билгели.

4.1.27. Законнар нигезендә халык алдында чаралар үткәрү белән бәйле бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

4.1.28. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын саклау буенча республика комиссиясе эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм матди-техник тәэмин итүне, шулай ук балигъ булмаганнарның күзәтүсез, тәрбиясез калуын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен профилактикалау мәсьәләләре, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өчен балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр, иҗтимагый берләшмәләр, дини оешмалар, бүтән оешмалар һәм гражданнар белән багланышларын тәэмин итә.

4.1.29. Юридик затларга үзләренең исемнәрендә «Татарстан Республикасы», «Татарстан» сүзләрен һәм алар нигезендә төзелгән сүзләр һәм сүз тезмәләрен (шул исәптән кыскартуларны) куллануга рөхсәтләр бирә.

4.1.30. Халыкны хокукый агартуда һәм хокукый мәгълүмат бирүдә катнаша.

4.1.31. Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча законнар нигезендә хокукый консультация бирү рәвешендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә.

4.1.32. Тормышта авыр хәлдә калган гражданнарга кичектергесез очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү буенча ведомствоара комиссия төзи.

4.1.33. Татарстан Республикасы Законнары җыентыгын әзерләү, бастырып чыгару һәм яңарту эшләрендә катнаша.

4.1.34. Министрлыкны тотуга һәм Министрлыкка йөкләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджет акчасын баш бүлүче һәм алучы вазыйфаларын гамәлгә ашыра.

4.1.35. Россия Федерациясе Югары Суды каршындагы Татарстан Республикасында Суд департаменты идарәсе белән берлектә җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм матди-техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

4.1.36. Җәмәгать судьялары аппаратларын кадрлар белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра, аларны яңадан укытуны һәм квалификацияләрен күтәрүне оештыра.

4.1.37. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларына гадел хөкемне тәэмин итү өчен кирәкле биналар (урыннар) бирүнең билгеләнгән тәртибен саклауны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

4.1.38. Җәмәгать судьялары һәм җәмәгать судьялары аппаратлары эшчәнлеген тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән мөлкәтне максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

4.1.39. Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары эшен оештыруны тикшерә.

4.1.40. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары структурасын һәм штат расписаниесен үзгәртү (раслау) турында тәкъдимнәр кертә.

4.1.41. Министрлык һәм җәмәгать судьялары аппаратлары эшчәнлегендә заманча мәгълүмат технологияләрен гамәлгә кертүне һәм файдалануны тәэмин итә.

4.1.42. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Министрлык ихтыяҗлары өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыра һәм дәүләт контрактлары төзи.

4.1.43. Мобилизация эше буенча чаралар башкаруны оештыра.

4.1.44. Министрлыкны, эшчәнлекләре министрлык эшчәнлеге белән бәйле яки аның карамагындагы оешмаларны мобилизациягә әзерләүне һәм мобилизацияләүне оештыру һәм тәэмин итә, шулай ук әлеге чараларны методик тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

4.1.45. Үз компетенциясе кысаларында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи.

4.1.46. Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча республика ведомствоара комиссиясе эшенә булышлык күрсәтә.

4.1.47. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен дәүләт һәм башка органнардан, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан кирәкле мәгълүматны, документларны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә сората һәм ала.

4.1.48. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның норматив хокукый аткларын, рәсми белдерүләрен бастыру, Министрлык компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча башка материалларны урнаштыру өчен басма массакүләм мәгълүмат чараларын билгели.

4.1.49. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә өчен чараларны гамәлгә ашыра.

4.1.50. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив хокукый актларында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## V. Министрлык эшчәнлеген оештыру

5.1. Министрлыкны министр җитәкли, ул Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә вазыйфасына билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә.

5.2. Министр Министрлыкка йөкләнгән вәкаләтләр үтәлеше һәм билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру өчен шәхси җавап тота.

5.3. Министрның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вазыйфага билгеләнә һәм вазыйфадан азат ителүче урынбасарлары бар, шул исәптән бер беренче урынбасар.

5.4. Министр:

5.4.1. Үзенә йөкләнгән эшчәнлек өлкәсендә шәхси идарә нигезендә җитәкчелекне гамәлгә ашыра.

5.4.2. Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәне раслый.

5.4.3. Үзенең урынбасарлары вәкаләтләрен билгели, алар арасында бурычларны бүлә, шулай ук Министрлык компетенциясенә карый торган оператив, оештыру-штат, кадрлар, финанс һәм бүтән мәсьәләләрне хәл итү буенча башка вазыйфаи затлар вәкаләтләрен билгели.

5.4.4. Билгеләнгән хезмәткәрләр саны һәм хезмәт өчен түләү фонды кысаларында Министрлыкның штат расписаниесен, шулай ук бүлеп бирелгән ассигнованиеләр кысаларында Министрлык аппаратын тотуга бюджет сметасын раслый, аның үтәлешен тикшерүдә тота.

5.4.5. Министрлык компетенциясе кысаларында чыгарылган боерыкларны имзалый, аларның үтәлешен тикшерүдә тота.

5.4.6. Министрлык һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, аларга карата бүләкләү чараларын куллана, законнар нигезендә дисциплинар һәм бүтән җаваплылыкка тарта.

5.4.7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча закон актлары һәм бүтән норматив хокукый актлар проектларын, шулай ук юстиция өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру буенча тәкъдимнәр кертә.

5.4.8. Үз компетенциясе кысаларында Министрлык, Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратлар хезмәткәрләрен аларга классы чиннар (законнарда билгеләнгән тәртиптә классы чиннар бирә), дәүләт бүләкләре, мактаулы исемнәр бирүгә тәкъдим итә.

5.4.9. Законнарда каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

5.5. Министрлык эшчәнлегенең аеруча мөһим мәсьәләләре Министрлык коллегиясе утырышларында карап тикшерелә.

5.6. Коллегия санын һәм составын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый.

5.7. Министрлык каршында координацияләүче, киңәшмә һәм фәнни-методик органнар (советлар, комиссияләр, төркемнәр) оештырыла ала. Әлеге органнарның составын һәм алар турында нигезләмәләрне министр раслый.

5.8. Министрлыкны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2006 ел, 22 февраль, 68 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 20 февраль, 103 нче
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы структурасы

Министр

Финанс бүлеге

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге

Министрның беренче урынбасары

Хокук экспертизасы һәм норма чыгару эшчәнлеге бүлеге

Норматив хокукый актларны теркәү һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлеге

Мәгълүмат-аналитик эш, координацияләү һәм планлаштыру бүлеге

Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү секторы

Министр урынбасары

Җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге

Җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру-хокукый тәэмин итү бүлеге

Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлеге

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппараты

Министр урынбасары

Җирле үзидарә һәм муниципаль регистрны алып бару өлкәсендә норматив хокукый эш бүлеге

Җирле үзидарә органнарына хокукый консультацион-методик ярдәм бүлеге

Җирле үзидарә тармагында территориаль оештыру һәм контрольне гамәлгә ашыру мәсьәләләре бүлеге

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү секторы

Министр ярдәмчесе

Эшләр идарәчесе

Оештыру эше һәм документлар әйләнеше бүлеге